ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423761, Аеш авылы, Ленин ур., 34б йорт.

СОВЕТ АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423761, село Аишево, ул. Ленина, дом 34б.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021г. №22

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Аеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Аеш авылы, Ленин урамы, 34б нче йорт; адреслары буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Аеш авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Аеш авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Аеш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Д.Р.Ахатов